РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ» ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА ГЛАВА ГОРОДА ЧИСТОПОЛЬ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫ**

***Постановление*** ***Карар***

19.03.2025 **Чистай шәһәре** № 30

Иҗтимагый фикер алышуларны
(ачык тыңлауларны) билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 16:54:030105:90 кадастр номерлы, 11525 кв. м мәйданлы, түбәндәге адрес буенча урнашкан җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча җәмәгать фикер алышуларын (ачык тыңлауларны) билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Тургенев урамы, 49 җ/к – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең «Кунакханә хезмәте күрсәтү» индивидуаль торак төзелеш зонасында (Ж1).
2. Иҗтимагый фикер алышуларны (ачык тыңлауларны) оештыручы - коллегиаль киңәшмә органы составын расларга:
1) И. Ф. Рәхимов – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе;
2) А. Р. Хаматов – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;
3) В. О. Маркин – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Шәһәрне җайга салу һәм инфраструктура үсеше» МБУ төзелеш контроле бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча);
4) А. А. Шумилов – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы;
5) М. Ю. Исхакова – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе;
6) Ф. И. Хәйруллина – Чистай, Спас районнарында Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор ҖЧҖ башлыгы (килешү буенча);
7) Л. Р. Хәлилова – «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итү идарәсе» МКУ баш белгече (килешү буенча).
3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:
3.1. Иҗтимагый фикер алышулар (гавами тыңлаулар) үткәрү вакыты – 2025 елның 2 апрелендә 14: 00 сәгатьтә.

3.2. Үткәрү срогы (дәвамлылыгы) – әлеге карар басылып чыккан көннән алып гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр бер айдан да артык түгел.
3.3. Үткәрү урыны – түбәндәге адрес буенча урнашкан Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының Конференц-залы: ТР, Чистай муниципаль районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт.
3.4. Иҗтимагый фикер алышуларда (ачык тыңлауларда) катнашуга гариза мәсьәләсе буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язма рәвештә түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: ТР, Чистай районы, Чистай шәһәре, К. Маркс урамы, 27 (эш көннәрендә – 9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр) яки электрон почта аша: Chis.Arhitek@tatar.ru.
3.5. Чыгыш ясау хокукы белән иҗтимагый фикер алышуларда (ачык тыңлауларда) катнашуга гаризалар бирү вакыты – 01.04.2025 елга кадәр.
4. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенә:
уздырыла торган иҗтимагый фикер алышулар (ачык тыңлаулар) буенча материалларны «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән кагыйдәләр нигезендә урнаштыруны тәэмин итәргә;
иҗтимагый фикер алышулар (ачык тыңлаулар) башлану турында хәбәр итүне тәэмин итәргә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы Д. А. Иванов